| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |
| --- | --- |
| ***БУА ШӘҺӘРЕ*** | ***ГЛАВА*** |
| ***БУА*** | ***ГОРОДА БУИНСКА*** |
| ***МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*** | ***БУИНСКОГО*** |
| ***БАШЛЫГЫ*** | ***МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА*** |

# КАРАР
# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

12 октябрь 2021 ел № 16

Татарстан Республикасы Буа муниципал районы
Буа шәһәренең 16:14:080303 номерлы кадастр
кварталының территорияләрен планлаштыру һәм
ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Буа шәһәр Советының 2021 елның 11 февралендәге 6-7 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәләр» нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципал районы Буа шәһәренең 16:14:080303 номерлы кадастр кварталының территорияләрен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында гавами тыңлаулар үткәрергә.
2. Татарстан Республикасы Буа муниципал районы Буа шәһәренең 16:14:080303 номерлы кадастр кварталының территорияләрен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча материалларны ТР Буа муниципаль районы сайтына урнаштырырга.
3. 2021 елның 12 октябреннән 10 ноябренә кадәрге чорда Татарстан Республикасы Буа муниципал районы Буа шәһәренең 16:14:080303 номерлы кадастр кварталының территорияләрен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча материаллар экспозициясен оештырырга.
4. 1 нче кушымта нигезендә кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә һәм расларга.
5. Гавами тыңлауларны 2021 елның 10 ноябрендә 11.00 сәгатьтә Буа шәһәре Башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Буа ш., Космовский ур., 91Б йорт.
6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә ТР Буа муниципаль районы сайтында bua@tatar.ru адресы буенча һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында

tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга. Вакыты - 2021 елның 18 октябренә кадәр.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Я. Галәветдиновка йөкләргә.

Буа муниципаль районы
Буа шәһәре Башлыгы Р.Р. Камартдинов

«ТР Буа муниципаль районы
Буа шәһәре Башлыгының
2021 елның 12 октябрендәге
16 номерлы карарына
кушымта

Территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| 1. Галәветдинов Р. Я. | Буа шәһәренең Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем рәисе (килешү буенча ) |
| 2. Гыйззәтов И.Г. | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетыҗитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| 3. Гыйльфанов Р.М. | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге башлыгы, эшче төркем рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 4. Маллямова И.З. | «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| 5.Гыймадиев И.И. | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) |